**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 март № 151

г. Казань

«2016 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасы турында

Татарстан Республикасында гражданнарны һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү, гамәлдәге федераль максатчан программалар кысаларында «Россия гражданнарына – һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак» өстенлекле илкүләм проектын тормышка ашыру чараларын финанслашуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «2016 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итү» программасы турында» 2015 ел, 17 март, 156 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\151.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 март, 151 нче карары белән расланды

**«2016 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасы**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2016 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаны яраштыручы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Программаның максаты | Гражданнарның торакка конституцион хокукын тормышка ашыру өчен уңай шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | Татарстан Республикасында керемнәре төрле дәрәҗәдә булган гражданнарны арзан бәяле торак белән тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын оештыру, гражданнар өчен торакның сатып алырлык булуын тәэмин итә торган финанс механизмнарын үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында милек хокукы яки наем нигезендә даими һәм вакытлыча яшәү өчен торакның нәтиҗәле базарын формалаштыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2016 ел |
| Программаны үтәүче | Махсуслаштырылган оешма – «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы (Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2005 ел, 23 июнь, ПУ-265 нче Указы) |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1. Татарстан Республикасында гражданнарны социаль ипотека системасында торак белән тәэмин итү, шулай ук яшь гаиләләргә – «2011 – 2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасында |

| | |
|---|---|
| | катнашучыларга торак реализацияләү, «2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы һәм башка торак программалары кысаларында төзелгән торакны авылдагы яшь белгечләргә реализацияләү максатларында, Программа чараларын кимендә 15 000,0 млн.сум күләмендә финанслау.<br>2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукын тормышка ашыручы гаиләгә, һәр бала туганда, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алынганда, гаиләне Махсуслаштырылган оешма реестрына керткән вакыттан 200,0 мең сум күләмендә, әмма Программаны финанслауның күздә тотылган күләмнәре нигезендә бала туган вакытка торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтеннән арттырмыйча – 1 250,0 млн.сум күләмендә сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү.<br>3. Татарстан Республикасы җирләре дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыру.<br>Татарстан Республикасы территориясендә, аны гражданнарга социаль ипотека системасында реализацияләү максатында, Программаны үтәүче тарафыннан төзелгән торак күләме мең 505,2 кв.метр тәшкил итәргә тиеш. Торак төзелешенең 1 кв.метры уртача кыйммәте 28,6 мең сумнан артмаска һәм, моннан тыш, инженерлык челтәрләренә чыгымнар иң күбе 2 мең сум тәшкил итәргә тиеш. 1 кв.метр торакның уртача кыйммәте, инженерлык челтәрләрен кертеп һәм төзелеш материалларына бәяләр артуны һәм инфляцияне исәпкә алып, тәгаенләнергә мөмкин.<br>Социаль ипотека системасында реализацияләнә торган 1 кв.метр торакның башлангыч кыйммәтен, төзелешне финанслаганда, җир кишәрлеген капиталлаштырганда гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны, күчемсез мөлкәт базары торышын исәпкә алып, махсуслаштырылган оешма билгели |
| Программаны финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыруны тәэмин итү чараларын финанслауга җибәрелә торган чыгымнарның гомуми күләме 15 000,0 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәгеләр хисабына:<br>Программаны яраштыручы һәм үтәүче арасында |

| | |
|---|---|
| | төзелгән килешү нигезендә, узган елгы акчаны күчерүне исәпкә алып, Программа чараларын үтәүгә Татарстан Республикасы оешмаларының 6 084,674 млн.сум күләмендәге түләүләре, шул исәптән Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыруны финанслауга – 6,319 млн.сум;<br>балалары туган яки аларны уллыкка (кызлыкка) алган гаиләләргә сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә акча – 1 250,0 млн.сум;<br>Программаны үтәүче акчасы – 7 665,326 млн.сум |
| Программаның үтәлешен тикшерүдә тотуны оешты-ру системасы | Эшчәнлекне тикшерүдә тоту һәм яраштыру Программаны яраштыручы тарафыннан тәэмин ителә |

## I. ПРОБЛЕМАНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2005 елдан башлап, социаль ипотека системасында торак төзелешен үстерү гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы халкына социаль ипотека системасында торак реализацияләү, гражданнарга һәм юридик затларга ипотека кредитлары бирү Программаның төп юнәлеше булып тора. Программа кысаларында торак йортлар, социаль, инженерлык инфраструктурасы объектларын төзүгә һәм төзекләндерүгә акча җәлеп ителә, республика халкын, шул исәптән яшь гаиләләрне һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү һәм торак төзелешен үстерү максатыннан чыгып, билгеләнгән тәртиптә торак объектлар сатып алына һәм реализацияләнә.

Аерым категориядәге гражданнарның керемнәре түбән булу һәм алар финанс институтларының тотрыклылыгына ышанмау сәбәпле, Программаны тормышка ашыру халыкның торак шартларын яхшырту өчен җыелган акчасын кыска вакытларда икътисадның реаль секторына кертергә ярдәм итә. Социаль ипотека системасында катнашучы гражданнар, акчаны киң масштаблы төзелешкә туплап һәм кертеп, торак проблемасын хәл итүнең уникаль ысулына ия була. Программа дәүләт хакимияте органнарының үзара тыгыз хезмәттәшлегендә гамәлгә ашырыла.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ АНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ВАКЫТЛАРЫ

Программаның максаты – гражданнарның торакка конституцион хокукын тормышка ашыру өчен уңай шартлар тудыру.

Программаның бурычы – Татарстан Республикасында керемнәре төрле дәрәҗәдә булган гражданнарны арзан бәяле торак белән тәэмин итүнең нәтиҗәле

системасын оештыру, гражданнар өчен торакның сатып алырлык булуын тәэмин итә торган финанс механизмнарын үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында милек хокукы яки наем нигезендә даими һәм вакытлыча яшәү өчен торакның нәтиҗәле базарын формалаштыру.

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2016 ел.

## III. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

1. Программа чараларын түбәндәге максатларда финанслауны гамәлгә ашыру:

Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән социаль ипотека системасында һәм башка торак программалары буенча тәэмин итү;

торакны яшь гаиләләргә – «2011 – 2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасында катнашучыларга реализацияләү;

төзелгән торакны «2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы кысаларында авылдагы яшь белгечләргә реализацияләү.

2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукын тормышка ашыручы гаиләгә, һәр бала туганда, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алынганда, гаиләне Махсуслаштырылган оешма реестрына керткән вакыттан 200,0 мең сум күләмендә, әмма бала туган вакытка торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтеннән арттырмыйча, сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү.

3. Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыру.

## IV. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

Программаны тормышка ашыру чараларын финанслауга җибәрелә торган чыгымнарның гомуми күләме 15 000,0 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәгеләр хисабына:

Программаны яраштыручы һәм үтәүче арасында төзелгән килешү нигезендә, узган елгы акчаны күчерүне исәпкә алып, Программа чараларын үтәүгә Татарстан Республикасы оешмаларының 6 084,674 млн.сум күләмендәге түләүләре, шул исәптән Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыруны финанслауга – 6,319 млн.сум;

балалары туган яки аларны уллыкка (кызлыкка) алган гаиләләргә сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә акча – 1 250,0 млн.сум;

Программаны үтәүче акчасы – 7 665,326 млн.сум.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаны яраштыручы Программаны үтәүче белән аны тормышка ашыру турында килешү төзи.

Программаны үтәүче төзелгән килешү нигезендә аны тулы күләмдә тормышка ашыруны оештыра һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына килешүдә билгеләнгән вакытлар һәм форма нигезендә Программаны тормышка ашыру турында хисаплар кертә.

Программаны тормышка ашыруның барышын тикшерүдә тоту аны яраштыручы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

## VI. ПРОГРАММАНЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ, СОЦИАЛЬ ҺӘМ ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

1. Программа түбәндәгеләрне хәл итәргә ярдәм итәчәк:

Татарстан Республикасында гражданнарны социаль ипотека программасы буенча торак белән тәэмин итү, торакны яшь гаиләләргә – «2011 – 2015 елларга «Торак» федераль максатчан программасының «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасында катнашучыларга реализацияләү, төзелгән торакны «2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы кысаларында авылдагы яшь белгечләргә һәм гражданнарның башка категорияләренә реализацияләү чараларын, 505,2 мең.кв.метр күләмендәге торакны эксплуатациягә кертеп, кимендә 15 000,0 млн.сум күләмендә финансларга;

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукын тормышка ашыручы гаиләгә, һәр бала туганда, шулай ук уллыкка (кызлыкка) алынганда, гаиләне Махсуслаштырылган оешма реестрына керткән вакыттан бер балага 200,0 мең сум исәбеннән 1 250,0 млн.сум күләмендә, әмма бала туган вакытка торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтеннән арттырмыйча, сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтергә;

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштырырга.

2. Татарстан Республикасы территориясендә төзелгән торак күләме 505,2 мең.кв.метр тәшкил итәргә тиеш.

---